# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай район Советы

Азнакай шәһәре № 249-35 «22» апрель 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2012 елның 28 апрелендәге «Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында» 139-20 номерлы карары белән расланган өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенә үзгәреш кертү турында
(22.10.2013 №274-37, 09.11.2017 №147-22, 12.11.2018 №211-31, 15.02.2019 №239-34 карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясына 2018 елның 22 декабрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән үзгәрешләр кертү сәбәпле, шулай ук Азнакай шәһәр прокурорының 2019 елның 28 февралендәге 02-08-02/202-2019 номерлы протестын исәпкә алып,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2012 елның 28 апрелендәге «Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында» 139-20 номерлы карары белән расланган өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенә (22.10.2013 №274-37, 09.11.2017 №147-22, 12.11.2018 №211-31, 15.02.2019 №239-34 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3,21,23 пунктларында «дача төзелеше» сүзләрен төшереп калдырырга.

Тәртипнең 1 нче кушымтасында 2 нче пункттагы «дача торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге» юлын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә: http://aznakayevo.tatar.ru. адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин